ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БИЕКТАУ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
АЛАН-БӘКСӘР
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ
422723 Татарстан Республикасы, Биектау районы,
Алан-Бәксәр авылы, Үзәк ур., 19 йорт

ИСПОНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
АЛАН-БЕКСЕРСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ВЫСОКОГОРСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
422723, Республика Татарстан, Высокогорский район
с. Алан-Бексер, ул. Центральная, д.19

Тел./факс: +7(84365) 63-9-51, e-mail: AlanB.Vsg@tatar.ru

**КАРАР** **ПОСТАНОВЛЕНИЕ**

**31.01.2024 ел** **№ 2**

**Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Алан-Бәксәр авыл җирлегендә җирләү хезмәтләренең гарантияләнгән исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләрнең бәясен раслау турында**

2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль закон, 1996 елның 12 гыйнварындагы 8-ФЗ номерлы «Җирләү һәм күмү эше турында» Федераль закон, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2024 ел 23 гыйнварындагы 46 номерлы «2024 елда түләүләр, пособиеләр һәм компенсацияләр индексациясе коэффициентын раслау турында» карары, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2007 елның 18 маендагы 196 номерлы «Татарстан Республикасында «Җирләү һәм күмү эше турында» Федераль законны гамәлгә ашыру чаралары турында» карары нигезендә, Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Алан-Бәксәр авыл җирлеге Башкарма комитеты **КАРАР БИРӘ:**

1. 2024 елның 1 февраленнән Биектау муниципаль районы Алан-Бәксәр авыл җирлегендә җирләү хезмәтләренең гарантияләнгән исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләрнең бәясен 1 нче һәм 2 нче кушымта нигезендә 8370,20 сум күләмендә билгеләргә һәм гамәлгә кертергә.
2. 2024 елның 1 февраленнән Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Алан-Бәксәр авыл җирлеге башкарма комитетының 2021 елның 15 апрелендәге 10 номерлы “Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Алан-Бәксәр авыл җирлегендә җирләү хезмәтләренең гарантияләнгән исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләрнең бәясен раслау турында” карарын көчен югалткан дип исәпләргә.
3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында: http://vysokaya-gora.tatarstan.ru/ веб-адрес буенча һәм Интернет-телекоммуникация челтәрендә «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталы»нда: http://pravo.tatarstan.ru веб-адрес буенча бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).
4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Алан-Бәксәр авыл җирлеге
Башкарма комитеты җитәкчесе З.Р.Гарифуллина

1 нче кушымта

РАСЛАНГАН
Татарстан Республикасы Биектау
муниципаль районы Алан-Бәксәр
авыл җирлеге Башкарма
комитетының 2024 елның 31 январе
№ 2 карары белән

**Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Алан-Бәксәр авыл җирлегендә җирләү хезмәтләренең гарантияләнгән исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләрнең бәясе**

| Хезмәтләр исеме | Хезмәтләрнең бәясе (сум) |
|---|---|
| 1. Мәет күмү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү | 0,00 |
| 2. Мәет җирләү өчен кирәкле табутны һәм башка әсбапларны бирү һәм китерү | 5542,30 |
| 3. Мәрхүмнең гәүдәсен (калдыкларын) зиратка китерү | 669,31 |
| 4. Җирләү (кабер казу һәм күмү) | 2158,59 |
| **Барлыгы** | **8370,20** |

2 нче кушымта
РАСЛАНГАН
Татарстан Республикасы Биектау
муниципаль районы Алан-Бәксәр
авыл җирлеге Башкарма
комитетының 2024 елның 31 январе
№ 2 карары белән

**Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Алан-Бәксәр авыл җирлегендә җирләү хезмәтләренең гарантияләнгән исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләрнең бәясе**

| Хезмәтләр исеме | Хезмәтләрнең бәясе (сум) |
|---|---|
| 1. Мәет күмү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү | 0,00 |
| 2. Кәфенләү | 301,18 |
| 3. Мәет җирләү өчен кирәкле табутны һәм башка әсбапларны бирү һәм китерү | 5241,12 |
| 4. Мәрхүмнең гәүдәсен (калдыкларын) зиратка китерү | 669,31 |
| 5. Җирләү (кабер казу һәм күмү) | 2158,59 |
| **Барлыгы** | **8370,20** |